РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕКИБЯКОЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Ленина, д. 31
село Верхние Кибя-Кози,
422083
тел.(884360) факс: 56-5-42
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин урамы, 31енчейорт,
Югары Кибәхуҗа авылы,
422083
тел. (884360) факс: 56-5-42
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318107 ОГРН 1061675010836 ИНН/КПП 1619004443/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№8** **«17» февраль 2021ел**

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә 2021 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 18 гыйнварындагы 73 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлешенең 15 пункты, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты:

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә 1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
3. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 31.01.2020 ел №2 карар үз көчен югалткан дип танырга.

Теләче муниципаль районы
Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге
башлыгы Ф.Р. Мәхмүтов

Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының «17» гыйнвар 2021 ел №8 карарына 1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл жирлегендә 2021 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 125,0 |
| 2.Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 2675,40 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 764,50 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2860,08 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының «17» гыйнвар 2021 ел №8 карарына 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә 2021 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 125 |
| 2.Тәнне кәфенләү | 1300,0 |
| 3.Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 1375,40 |
| 4. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 764,50 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2860,08 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |